РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
0, Республика Татарстан, Сабинский
район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 2-27-05

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘРДӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шәмәрдән авылы, Лермонтов урам,
2 йорт
тел. (84362) 2-27-05

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

17.12.2025 | № 15

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 28.04.2018 ел, №10 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 ел, №182 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.11.2025 ел, №994 карары нигезендә муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр", Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге советы

Карар кылды:

1. Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 28.04.2018 ел, №10 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына (советның 09.11.2020 ел, №11, 21.10.2022 ел, №19, 19.12.2022, №25, 29.08.2024 №16, 13.11.2024 №25, 25.04.2025 №13 карарлары редакциясендә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 16 928 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керешкән яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shemordan/.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы А.К.Вәлиев

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының
17.12.2025 № 15 карарына

Саба муниципаль районының Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре |
| --- | --- |
| Авыл җирлеге башлыгы | 27 601 |
| Депутатлар | 16 928 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 16 928 |